**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының "Норма авыл жирлеге" муниципаль берәмлеге чикләрен «Балтач шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә үзгәртү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар үткәрү нәтиҗәләре турында бәяләмә**

Норма ав. 16.01.2026

Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге башлыгының 25.12.2025 ел, № 19 карары нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Норма авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге чикләрен Балтач шәһәр тибындагы поселогы белән чиктәш җирдә үзгәртү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар уздырылды.

Үткәрү вакыты һәм урыны:14.01.2026 11:00 сәгатьтә түбәндәге адрес буенча: ТР, Балтач муниципаль районы, Норма авылы, Казан урамы, 1нче йорт.

Катнашучылар саны: 20 кеше.

Гавами тыңлауларга әзерлек чорында Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Норма авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге чикләрен «Балтач шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә үзгәртү буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кермәде.

2026 елның 14 нче гыйнварында гавами тыңлаулар вакытында гавами тынлауларда катнашучылардан искәрмәләр һәм тәкъдимнәр кермәде, гражданнарның хокукларын бозу һәм аларның мәнфәгатьләрен чикләү ачыкланмады. Чикләрне үзгәртү инициативасы бертавыштан хупланды.

Әлеге мәсьәлә буенча гавами тыңлауларны узган дип танырга һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Норма авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге чикләрен «Балтач шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә үзгәртүне максатка ярашлы дип санарга.

Әлеге бәяләмәне Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) бастырып чыгару юлы белән халыкка җиткерергә.

Рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Норма авыл җирлеге башлыгы Р. Н. Шәрипҗанов